# Сыйрышбаш авылы китапханўсе





Бөек Ватан сугышының утлы кырларыннан йөздән ни бары өчесе генә урап кайта алган буын вәкиле, күренекле шагыйрь, галим, Салават Юлаев исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Башкортстанның атказанган фән эшмәкәре Гыйлемдар Җиһандар улы Рамазанов 1923 елның 16 июнендә Чакмагыш районының Иске Балак авылында ярлы крестьян гаиләсендә туган. Туган авылында башлангыч мәктәпне, 1938 елда күрше Тайняш авылындагы җидееллык мәктәпне тәмамлагач, ул Уфа педагогия училищесына укырга керә. 1939-1941 елларда Дәүләкән башкорт педагогия училище-сында укый. 1941 елның азагында Кызыл Армия сафына алына. Башта Уфадагы хәрби пехота училищесында, ә 1942 елның мартыннан Уфадагы 30 чы укчы полкта курсант була.

1942 елның маеннан фронтка китә. Калинин фронтында, Великие Луки һәм Белый калалары янындагы сугышларда катнаша.

1943 елның июлендә Курск дугасында оборона сугышларында була. 1943 елның августында шунда, фронтта, Гыйлемдар Рамазанов Коммунистлар партиясе сафына кабул ителә. 1943-1944 елларда Украинаны азат итү сугышларында катнаша,1945 елда Польша, Германия, Австрия җирләре аша яу белән уза. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен II дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз ордены, медальләр белән бүләкләнә. Гыйлемдар Рамазанов 1945 елның җәендә армиядан демобилизацияләнә, шул елның көзендә Башкорт педагогия институтының тел һәм әдәбият факультетына укырга керә.

Институтны тәмамлагач, 1949-1950 елларда Бөре

ка. учылар институтында һәм педагогия

уч шкорт теле һәм әдәбияты укыта.



Гыйлемдар Рамазанов 1950-1953 елларда М.В. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының филология факультеты каршындагы аспирантурада укый. 1953 елда “Башкорт поэзиясендә совет кешесе образы” дигән темага кандидатлык диссертациясен яклый. 1955-1958 елларда Гыйлемдар Рамазанов “Совет Башкортстаны” гәзите мөхәррире булып эшли. Калган бөтен гомере СССР Фәннәр академиясенең Башкортстан филиалы Тарих, тел һәм әдәбият институтында өлкән гыйльми сотрудник. Гыйлемдар Рамазанов 1966 елда Мәҗит Гафури иҗаты турында докторлык диссертациясен яклады.

Гыйлемдар Рамазановның беренче шигырьләре матбугатта 1939 елда әдәби альманах һәм “Яшь төзүче” газетасы битләрендә күренгәли башлый. Яшь шагыйрьнең иҗаты үсә баруы һәм актив әдәби эшмәкәрлеге Бөек Ватан сугышы елларына туры килә. Шагыйрьнең “Безнең буын” исемендәге тәүге китабы 1947 нче елда дөньяга чыга. “Якты юллар”, “Сөю сүзе”, аеруча “Яшьлек юллары” дигән китаплары белән Г. Рамазанов үзен өлгереп җиткән шагыйрь итеп таныта.

Гыйлемдар Рамазановның сугыштан соң язылган күпчелек шигырь һәм поэмалары үз буыны-яшьтәшләре образын сурәтләүгә арналганнар. Бу яктан аеруча “Идел буендагы калада” һәм “Яшьлек таңнары” дигән поэмалары аерылып тора. Автор бу әсәрләрендә яшьләрнең сугыштан соң тыныч төзелеш шартларындагы тормыш юлларын, бай хыялларын һәм хезмәттәге казанышларын җырлый.




Гыйлемдар Рамазановның “Әти янында” (1964) дигән поэмасы Бөек Ватан сугышында һәлак булып калган әтисенең якты истәлегенә багышланган. Г. Рамазанов - уннан артыгырак поэма авторы.

Гыйлемдар Рамазанов - әдәбият белгече булып та танылган әдип. Аның башкорт әдәбияты турында газета-журналларда басылган дистәләгән мәкаләләреннән тыш, “Башкорт поэзиясендә совет кешесе образы”, “Әдәбият офыклары” дигән китабы, “Мәҗит Гафури иҗаты” исемле зур монографиясе бар. Рамазанов тәрҗемә эше белән дә шөгыльләнә. Аның А.С. Пушкин, М.Ю. Лермонтов, Н. А. Некрасов, А. Кулешов әсәрләреннән башкортчага тәрҗемәләре бар. Ю. Лаптевның ”Таң” дигән повесты аның тәрҗемәсендә башкортча аерым китап булып чыкты.

Гыйлемдар Рамазанов үзенең гыйльми, әдәби һәм журналистик эшчәнлеген җәмәгать һәм дәүләт эше белән бәйләп алып барды. Ул СССР Югары Советы депутаты, байтак еллар дәвамында Башкортстан Журналистлар берлеге рәисе, Башкортстан Язучылар берлеге идарәсе, “Уральский следопыт”, “Агыйдел” журналлары мөхәррияте әгъзасы булды. Әдәбият өлкәсендә күрсәткән хезмәтләре һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен Хезмәт Кызыл Байрагы, “Почет Билгесе” орденнары белән бүләкләнде, Салават Юлаев исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. Башкорт АССР-ының атказанган фән эшлеклесе.


1950 елдан бирле СССР Язучылар союзы әгъзасы.




# Гыйлемдар Рамазанов китаплары:

Безнең буын: Шигырьләр. –Уфа, 1947, 62 бит.
Якты юллар: Шигырьләр. –Уфа,1952, 77 бит.
Земля родная: Стихи. - Уфа,1954, 72 стр.
Сөю сүзе. Поэма һәм шигырьләр. – Уфа, 1955, 82 бит.
Башкорт поэзиясендә совет кешесе образы. Тәнкыйть- библиографик күзәтү. - Уфа, 1956, 136 бит.
Яшьлек юллары: Шигырьләр, поэмалары. –Уфа, 1958, 336 бит.
Огни за Белой-рекою: Стихи. - Уфа, 1959, 144 стр.
Зори молодости: Стихи и поэма. - М., “Советский писатель”, 1959, 136 стр.
Яшә, яшьлек! Шигырьләр. - Казан, 1959, 92 бит.
Гаҗәп сәяхәт: Балалар өчен шигырьләр. - Уфа, 1959, 60 бит.
Урал поэмасы: Поэма һәм шигырьләр. – Уфа, 1960, 150 бит.
Авыл кызы: Балалар өчен шигырьләр. - Уфа, 1962, 48 бит.
Сөям сине: Шигырьләр һәм поэма. – Уфа, 1963, 116 бит.
Стихи. - М., Гослтитиздат, 1963, 232 стр.
Мәҗит Гафури иҗады: Монография.- Уфа, 1965, 458 бит.
Әти янында: Поэма һәм шигырьләр. – Уфа, 1966, 90 бит.
Разговор гор: Поэма и стихи. - Уфа, 1967, 111стр.
Свидание с отцом: Стихи. - М., “Советская Россия”, 1968, 191 стр.
Шигырьләр һәм поэмалары. – Уфа, 1968, 191 бит.
Байрак турында поэма. - Уфа,1970, 30 бит.
Творчество Мажита Гафури. - Уфа, 1970, 302 стр.
Конец лета: Стихи. - Уфа, 1972, 63 с.
Сайланма әсәрләр. Т.1. Шигырьләр. - Уфа, 1972, 208 бит; Т.2. Поэмалар. - Уфа, 1973, 208 бит.
Беспокойство: Стихи. - М., “Правда”, 1973, 31 с.
Полвека: Стихи и поэма. - М., “Советская Россия”, 1974, 191 с.
Илле яшьтәгеләр: Шигырьләр һәм поэмалар. - Уфа, 1975, 112 бит.

В стране Салавата: Стихи и поэмы. - М., “Современник”, 1975, 127 с.
Слово солдата: Стихи и поэмы. - Уфа, 1976, 127 с.
Ветер из Башкирии: Стихи и поэмы. - М., “Дет. литература”, 1977, 46 с.
Горизонты литературы: Исследования и литературно-критические статьи. - Уфа, 1978, 192 стр.
Две реки. Стихи и поэма. - М., “Советский писатель”, 1978, 95 с.
Город над Агиделью: Фотоальбом. Уфа, 1978, 110 с.
Звезды за бой, звезды за труд. М., “Политиздат, 1979, 264 с.
Җирән кашка. Шигырьләр һәм поэмалар. Уфа, 1980, 40 бит.
Многоцветье. - М., “Современник”, 1980, 240 с.
Мажит Гафури: Очерк жизни и творчества. - М., 1980, 160 стр.
Надежда: Стихи и поэмы. - Уфа, Башкнигоиздат, 1982, 159 с.
Башкирская баллада: Стихотворения и поэмы. - Уфа, 1983, 142 с.
Алтмыш адым: Шигырьләр һәм поэмалар. - Уфа,1983, 536 бит.
Яшьлектә кунакта: Шигырьләр һәм поэма. - Казан, 1983, 144 бит.
Яуларда чыныккан мәхәббәт.- Уфа, 2005, 136 бит.












Ғилемдар Рамазанов
заман еле


Ғилемдар Рамазанов
АЛТМЫШ АҘЫМ


ЮЛДАРЫ


Ғ. Рамазанов



Ғилемдар Рамазанов
ҠЫҘЫЛ МАЙҘАН


ПОДВИГ
Гилемдар Рамазанов
СЛОВО СОЛДАТА


Ғилемдар Рамазанов
ӘҘӘБИӘТ ОФОКТАРЫ


Ғилемдар Рамазанов
БАЙРАҠ ХАҠЫНДА ПОЭМА


ГИЛЕМДАР РАМАЗАНОВ
НАДЕЖДА



# Ижаты һәм тормыш юлы турында:

Кулибай, С. Өч җыентык турында, “Әдәби Башкортстан”, 1949, №1.
Бабичев, Д. “Якты юллар”, “Әдәби Башкортстан”, 1952, №8.
Хөсәенов, Г.. Шагыйрьнең яшьлек юллары, (Баш сүз), “Яшьлек юллары”, Уфа, 1958.
Сафиуллин, Н. “Таулар җыры”, “Әдәби Башкортстан”, 1960, №7.
Шкавро, Л. Песни ясных зорью (Рецензия на книгу “Зори молодости”), “Урал”, 1960, №12.
Виноградов, В. Гражданин, коммунист, поэт. (Предисловие к книге стихов). В кн.: Стихи, М., Гослитиздат, 1963.
Нигъмати, Р. “Яңа юллар” , “Яшьлек юллары” (Р. Нигъмәти. Әсәрләр, (Өченче өстәлмә том), Уфа, 1964.
Гали, М. Зори молодости (О книге “стихи”), “Литературная Россия”, 1964, 10 апреля.
Краснов, Г. И страна и сердце – заодно. ( о книге «Стихи»), «Урал», 1964, №6.
Латынина А. Не уйти тебе от горения…, Журнал «Знамя»,1963,№1.
Исхаков, В. Зур хезмәт, “Агыйдел”, 1967, №9.
Шариф, А. Творчество Мажита Гафури, “Вопросы литературы”, 1967, №4.
Баимов, Р. Заман тавышы, “Агыйдел”, 1972, №4.
Хөсәенов, Г. Тынгысыз юлчы, дәртле җырчы, “Агыйдел”, 1972, №6.
Закруткин, В. Навсегда полюбив эту землю, “Лит. газета” , 1973, 28 марта.
Росляков, В. Память не дающая покоя, «Лит. газета», 1973, 13 июня.
Ульяшов, П. “Узнал я пути войны...”, “Дружба народов”, 1975, №5.
Ахмедьянов, К. Романтика подвигов, “Урал”, 1976, №7.
Смирнов, В. Листая жизни календарь, “Волга”, 1976, №12.

Широков, В. О книге “В стране Салавата”. “Новый мир”, 1976, №10.
Хөсәенов, Г. Тынгысыз юлчы, дәртле җырчы, “Шагыйрьләр”, Уфа, 1981.
Сафуанов, С. Тынгы белми торган юлчы мин..., “Агыйдел”, 1983, №6.
Рамазанов, Г. Библиографик күрсәткеч, Уфа, 1983.
Ахунов, Г. Игелекле кеше турында монолог //Тулпар, 1998, №2.
Габидуллина Ф. Иреннәрем кибеп ярылганда Шифалы су булдың, мәхәббәт //Кызыл таң.
Гыйлемдар Рамазанов. “Язылмаган китап”, Уфа, 1998
Хөсәенов. Г. Гыйлемдар Рамазанов, “Язмышыма язганы”, Уфа, 2001.
Таһирова, Ә. Үлемнәрне җиңәр җырлар бар... Йолдызлы аклан моны”, Уфа, 2007.









Гилемдар Рамазанов с дочерью Гульназ.










Мустай Карим, Шариф Биккул, композитор Рауф Муртазин, Гилемдар Рамазанов.



Гилемдар Рамазанов (справа) с боевыми друзьями на фронте.





Башкирские писатели — участники Великой Отечественной войны.

**Библиографик кїрсўткеч Гыйлемдар Рамазановны‹ и•аты һўм тормыш юлы белўн кызыксынучыларга тўкъдим ителў.**




Адрес:
Чакмагыш районы,
Сыйрышбаш авылы,
Музипов урамы, 75 А

БИБЛИОГРАФИК КYРС™ТКЕЧ
Тїзїчесе: Магалимова И.Н.